ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.7, пос. Октябрьский,
422580

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 7 нче йорт, Октябрҗский авылы,
422580

Тел.: (84379) 31-4-27, факс: (84379) 31-4-27.

.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге  Матюшино авылы гражданнары җыенының нәтиҗәләре турында

14.12.2024 №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,  "Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Матюшино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Матюшино авылында 2025 елда үзара салымны 2600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, чистарту, су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлауга, төзүгә һәм ремонтлауга юнәлтергә сез ризамы? - дигән мәсьәлә буенча 2024 елның 14 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 68 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 56 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «Әйе»  позициясе өчен гражданнар җыенында 56 катнашучы тавыш бирде;
-«Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде
- тавыш бирүдән тыелып калган җыенда 0 катнашучы.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Матюшино авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Матюшино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Матюшино авылында 2025 елда үзара салымны 2600 сум күләмендә

кертергә һәм алынган акчаларны су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, чистарту, су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлауга, төзүгә һәм ремонтлауга юнәлтергә сез ризамы? - дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Матюшино авылының гражданнар җыены нәтиҗәләрен Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Ш. Р. Азизов